РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» февраль 2024 ел г. Альметьевск № 729

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Чернобыль атом электростанциясендәге һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны исәпкә кую һәм аларга Дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 1091 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Социаль өлкәдә ярдәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Чернобыль атом электростанциясендәге һәлакәт,«Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны исәпкә кую һәм аларга Дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 1091 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 13 октябрендәге 2341 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтада:

1 бүлекнең 1.3.3.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.3.5. Социаль өлкәдә ярдәм үзәкләштерелгән цифрлы платформаның федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша.»;

1 бүлегенең 1.6 пунктында һәм аннан соң бөтен текст буенча ЕГИССО сүзен тиешле килештә социаль өлкәдә ярдәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов